**СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 елның «28» августыннан № 66

**«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгының «Россия Федерациясендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 02 маендагы 59-ФЗ Федераль закон таләпләре нигезендә гражданнарны шәхси кабул итүне оештыру турында» 2014 елның 28 ноябрендәге 39 номерлы карарына өстәмәләр кертү хакында»**

. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрының беренче урынбасары Р. Ф. Вәлиуллов уздырган «Ата-аналары алимент түләүдән качып йөрүче балигъ булмаган гаиләләргә хокукый ярдәм күрсәтү өчен республика муниципаль берәмлекләрендә бердәм кабул итү көнен уздыруны оештыру турында»гы мәсьәлә буенча киңәшмәнең 1 нче номерлы беркетмәсенең 3 пунктына таянып, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгының «Россия Федерациясендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 02 маендагы 59-ФЗ Федераль закон таләпләре нигезендә гражданнарны шәхси кабул итүне оештыру турында» 2014 елның 28 ноябрендәге 39 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- «2.1. Алимент түләүләрен түләтүне тәэмин итү мәсьәләсе буенча гражданнарны кабул итүнең бердәм көне итеп һәр айның беренче сишәмбесен билгеләргә.

2.2. Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгының коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча ярдәмчесен Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының җирле үзидарә органнарында алимент түләүләрен

түләтүне тәэмин итү мәсьәләсе буенча гражданнарны бердәм кабул итү көнен үткәрү буенча җаваплы зат итеп билгеләргә.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында һәм «Яңа Чишмә хәбәрләре» район газетасында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

**Яңа Чишмә**
**муниципаль районы Башлыгы** **В.М. Козлов**